РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**17.08.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№23/2**

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Чистай шәһәр
Советының 2022 елның 10
февралендәге «Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль
берәмлеге территориясендә
муниципаль торак контроле турында
Нигезләмәне раслау хакында»гы
13/3 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

Советның 2022 елның 10 февралендәге 13/3 номерлы карарына 2023 елның 30 июнендәге 02-08-02-2023 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Чистай шәһәр Советының 2022 елның 10 февралендәге 13/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.2 пунктында:

“энергетика нәтиҗәлелеге” сүзләреннән соң беренче абзацны “Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында законнар” белән тулыландырырга;

12 нче пунктка түбәндәге эчтәлек өстәргә:

“12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз

эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күп фатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын тотуга таләпләр.”

1.2. 1 бүлегенең 1.6 пунктының 1-3 пунктчаларында “1-11” саннарын “1-12” саннары белән алыштырырга.

1.3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы 2-3 пунктлары үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның 1.1.һәм 1.2 пунктлары 2023елның 01 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары М.И. Ксенофонтовка йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов